# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«22» 06 2022 ел Яр Чаллы ш. № 1848

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» район программасын раслау хакында» 2020 елның 21 декабрендәге 4850 номерлы карарга үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясен, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 20 августындагы 718 номерлы карары белән расланган «Россия милләтенең бердәмлеген ныгыту һәм Россия халыкларының этномәдәни үсеше (2014-2020 еллар)» федераль максатчан программасын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе турында» 2013 елның 26 июлендәге ПУ-695 номерлы Указын үтәү йөзеннән, «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон, «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» район программасын раслау хакында» 2020 елның 21 декабрендәге 4850 номерлы карарга үзгәрешләр кертергә: «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» программасының «Программаны тормышка ашыру буенча чаралар» 2 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта нигезендә).
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 06 1848 номерлы карарына 2 кушымта

**Тукай муниципаль районында «2021-2025 елларга милли сәясәтне гамәлгә ашыру» программасын тормышка ашыру буенча чаралар**

| № | Чаралар исеме | Финанс чараларын бүлү, еллар буенча (мең сумда) | | | | | Финанслау чыганагы | Башкаручы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | | |
| 1. | «Раштуа», «Колядки», «Нәүрүз» | 0,00 | 0,00 | 20 000 | 20 000 | 20 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 2. | «Сабантуй Гүзәле» - район кызлары арасында матурлык конкурсы | 0,00 | 0,00 | 30 000 | 30 000 | 30 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 3. | «Сабантуй» - район милли бәйрәме | 1000 000 | 1 406 078. 48 | 10 000 | 10 000 | 10 000 | Иганәче ярдәме | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 4. | «Петрау көне» - керәшен йола бәйрәме | 10,00 | 10 000 | 10 000 | 10 000 | 10 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 5. | «Иван Купала» бәйрәме - йола бәйрәме | 30 000 | 10 000 | 30 000 | 30 000 | 30 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | «Uen Fest- Уен Фест» традицион уеннар фестивале | 60 000 | 40 000 | 60 000 | 60 000 | 60 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 7. | «Түгәрәк уен» бөтенроссия татар фольклоры фестивале | 60 000 | 0,00 | 60 000 | 60 000 | 60 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 8. | Бөтенроссия Спас ярминкәсе (Алабуга шәһәре) | 10 000 | 10 000 | 10 000 | 10 000 | 10 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 9. | «Чатыр тауда җыен» төрки халыкларның республика фольклор фестивале (Азнакай шәһәре) | 18 000 | 10 000 | 18 000 | 18 000 | 18 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 10. | «Питрау» керәшеннәрнең республика халык бәйрәме, «Керәшен чибәре» конкурсы (Мамадыш районы Җөри авылы) | 30 000 | 15 000 | 30 000 | 30 000 | 30 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 11. | «Русская песня» республика конкурсы (Казан шәһәре) | 20 000 | 0,00 | 20 000 | 20 000 | 20 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 12. | «Каравон» рус җыры республика фестивале (Лаеш районы Никольское авылы) | 20 000 | 40 000 | 20 000 | 20 000 | 20 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 13. | «Рождественская звезда» республика | 24 000 | 38 000 | 24 000 | 24 000 | 24 000 | Район бюджеты | «Тукай |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | фестиваль-конкурсы (Казан шәһәре) | | | | | | | муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 14. | «Иске Казан -Түгәрәк уены» республика татар фольклоры фестивале (Казан шәһәре) | 20 000 | 0,00 | 20 000 | 20 000 | 20 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 15. | «Истоки» фольклор коллективларының район фестивале (Яр Чаллы шәһәре) | 0,00 | 0,00 | 100 000 | 100 000 | 100 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 16. | «Әйлән-бәйлән» Татарстан халыклары традицион уеннарының Балалар республика фестивале (Әлки районы Базарлы Матак авылы) | 35 000 | 0,00 | 35 000 | 35 000 | 35 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 17. | «Театр Олимпы» III район фестиваль-конкурсы | 77 000 | 17 000 | 77 000 | 77 000 | 77 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 18. | «Халкым минем» Тукай муниципаль районы территориясендә урнашкан авыл җирлекләре арасында иҗат коллективлары һәм ялгыз башкаручылар смотр-конкурсы | 50 000 | 17 921.52 | 50 000 | 50 000 | 50 000 | Район бюджеты | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 19. | Дини конфессияләр, милли берләшмәләр вәкилләре, уку йортлары җитәкчеләре, галимнәр катнашында җәмгыятьтә әхлакый сәламәтлекне ныгыту проблемалары буенча «түгәрәк өстәл» утырышын уздыру, массакүләм-мәгълүмат чараларында яктырту | - | - | - | - | - | Агымдагы чыгымнар | «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 20. | Яшьләр даирәсендә терроорчылык һәм | 15 000 | 15 000 | 15 000 | 15 000 | 15 000 | Район бюджеты | «Мәгариф |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | экстремизмны профилактикалау өлкәсендә иң яхшы программага (проектка) чыгарылыш сыйныф укучылары арасында конкурслар һәм олимпиадалар оештыру. Бу өлкәдә укучыларның актив катнашында уңышлы башкарылган комплекслы тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өчен махсус премияләр гамәлгә кую һәм түләү | | | | | | | идарәсе» МКУ |
| 21. | Барлык төр мәгариф учреждениеләрендә укучыларның актив катнашу рәвешләрен куллана торган чараларны даими рәвештә үткәрүне тәэмин итү:<br>- «Дуслыкта безнең көч» темасы буенча рус һәм татар шагыйрьләренең әсәрләрен укучылар конкурсы;<br>- Этникара һәм төбәкара татулык шартларында яшәү ихтыяҗын формалаштыру һәм ныгыту максатыннан «Минем күп милләтле төбәгем» темасы буенча видеороликлар конкурсы | 10 000 | 10 000 | 10 000 | 10 000 | 10 000 | Район бюджеты | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 22. | Яшүсмерләр арасында экстремизмны кисәтү максатыннан үткәрелгән республика конкурсында катнашу һәм аларны балалар һәм яшьләр оешмалары эшчәнлегендә тормышка ашыру. «Экстремизмга-юк!» плакатлар һәм рәсемнәр конкурсы | 10 000 | 10 000 | 10 000 | 10 000 | 10 000 | Район бюджеты | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 23. | Прокуратура, башкарма хакимият органнары, төрле дини конфессияләр һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре катнашында террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча яшьләр белән «түгәрәк өстәл» форматында яшьләр форумнары үткәрү | - | - | - | - | - | Финансламыйча | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 24. | Үсеп килүче буынның һәм яшьләрнең әхлакый сәламәтлеген ныгыту проблемалары буенча аңлату әңгәмәләре үткәрү | - | - | - | - | - | Финансламыйча | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 25. | «Экстремизмга-юк!» акциясе. Район паркларында, скверларында ФОРПОСТ һәм ОППН отрядлары әгъзалары тарафыннан урамда листовкалар тарату | - | - | - | - | - | Финансламыйча | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| **БАРЛЫГЫ** | | **1499** | **1649** | **1649** | **1649** | **1649** | | |